# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Ютазы тракты (4 йорт, 14 йорт) буенча 2023 елда гражданнардан үзара салым кертү турында**

**14 ноябрь 2022 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре Ютазы тракты (4 йорттан 14 йорт) буенча гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән (Ютазы тракты урамы (4 йорт буенча 14 йорт) балигъ булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, 1 төркеме инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге формада белем алучы студентлардан, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән махсус хәрби операциягә киткән гаиләләрдән кала 5000,0 (биш мең ) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

"Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең Ютазы тракты урамы, 4 нче йорттан 14 нче йортка кадәр, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларны карап тоту (юлларга асфальт-бетон җәю, сатып алу, төяү, ташу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)".

3. Әлеге карарны, кабул ителгән көннән соң 2 көн эчендә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Л. Ф. Миндубаева